КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 17 декабрь г.Казань № 1156

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбенә төзелгән (реконструкцияләнгән) күчемсез мөлкәт объектларын үз вакытында тапшыруны тәэмин итү регламентын раслау турында» 2016 ел, 24 май, 338 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбенә төзелгән (реконструкцияләнгән) күчемсез мөлкәт объектларын үз вакытында тапшыруны тәэмин итү регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбенә төзелгән (реконструкцияләнгән) күчемсез мөлкәт объектларын үз вакытында тапшыруны тәэмин итү регламентын раслау турында» 2016 ел, 24 май, 338 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 24 октябрь, 1341 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбенә төзелгән (реконструкцияләнгән) күчемсез мөлкәт объектларын үз вакытында тапшыруны тәэмин итү регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктта «Татарстан Республикасы Баш инвестиция-төзелеш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе (алга таба - Башинвесттөзелеш)» сүзләрен «Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы (алга таба - Төзелеш министрлыгы), «Татарстан Республикасы Баш инвестиция-төзелеш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе һәм «Татарстан Республикасы

Баштөзелеш» дәүләт бюджет учреждениесе йөзендә дәүләт заказчылары (алга таба - дәүләт заказчылары)» сүзләренә алмаштырырга;

1.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Җир һәм мөлкәт министрлыгының, Төзелеш министрлыгының, дәүләт заказчыларының җирле үзидарә органнары һәм эксплуатацияләүче оешмалар белән үзара хезмәттәшлеге Россия Федерациясе Граждан кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы федераль законнар, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Төзелешкә рөхсәт формасын һәм объектны эксплуатациягә кертүгә рөхсәт формасын раслау турында» 2022 елның 3 июнендәге 446/б номерлы боерыгы (алга таба - Россия Төзелеш министрлыгының 446/б номерлы боерыгы) нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

1.3 пунктта «Башинвесттөзелеш гамәлгә ашыра» сүзләрен «дәүләт заказчылары гамәлгә ашыра» сүзләренә алмаштырырга;

1.4 пунктта «дәүләт заказчысы - Башинвесттөзелеш» сүзләрен «дәүләт заказчылары» сүзләренә алмаштырырга;

2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Төзелеш министрлыгы, шәһәр округының җирле үзидарә органнары (килешү буенча) Мөлкәткә карата объектны эксплуатациягә кертүгә рөхсәт бирелгән көннән алып 30 календарь көн эчендә дәүләт заказчысына озату хаты белән Россия Төзелеш министрлыгының 446/б номерлы боерыгы нигезендә рәсмиләштерелгән объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт күчермәсен, проект документациясендә, шул исәптән инженерлык челтәрләренең, каралган күчемсез мөлкәт объектларын дәүләт кадастр исәбенә куюны раслый торган документлар җибәрә.»;

2.2 пунктта «Башивесттөзелеш» сүзен «Дәүләт заказчысы» сүзләренә алмаштырырга;

2.3 пунктның беренче абзацында «Башивесттөзелеш» сүзен «дәүләт заказчысы» сүзләренә алмаштырырга;

2.4 пунктта «Башивесттөзелеш» сүзен «Дәүләт заказчысы» сүзләренә алмаштырырга;

2.5 пунктта:

беренче абзацта «Башивесттөзелеш» сүзләрен «дәүләт заказчысы» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «Башивесттөзелеш» сүзен «Дәүләт заказчысы» сүзләренә алмаштырырга.

2.6 пунктта «Башивесттөзелеш» сүзен «Дәүләт заказчысы» сүзләренә алмаштырырга;

2.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.7. Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы, дәүләт заказчысы, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) эксплуатацияләүче оешмалар тарафыннан имзаланган Мөлкәтне кабул итү-тапшыру актлары проектлары кергән көннән алып 10 эш көне эчендә, Мөлкәтне кабул итү-тапшыру актлары карый һәм имзалый, бу хакта дәүләт заказчысына, җирле үзидарә органнарына һәм (яисә) эксплуатацияләүче оешмаларга

өч эш көне дәвамында хәбәр итә яисә ачыкланган кисәтүләрне бетерү өчен дәүләт заказчысына Мөлкәтне кабул итү-тапшыру актлары проектларын кире кайтара.

Дәүләт заказчылары кисәтүләр алган көннән алып 10 эш көне эчендә Җир һәм мөлкәт министрлыгына эшләп бетерелгән, дәүләт заказчылары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) эксплуатацияләүче оешмалар тарафыннан имзаланган Мөлкәтне кабул итү-тапшыру актларын җибәрә.»;

2.8 пунктта «Башинвестстөзелеш» сүзен «Дәүләт заказчысы» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин